ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2023 ел № 22/7

Муниципаль учреждениеләр
хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү
өлкәсендәге аерым Шәһәр Советы
карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 сентябрендәге 987 номерлы карары, шәһәр Уставының 28 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турындагы Нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

Шәһәр Советы

**КАРАР бирде:**

1. Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/7 номерлы Карары белән расланган «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктта:

- 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) База оклады (база вазыйфа оклады), хезмәт хакының база ставкасы - тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче яки хезмәткәр вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы дәүләт яки муниципаль учреждение хезмәткәренең, компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, минималь окладының (вазыйфа окладының), хезмәт хакы ставкасы.»;

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Оклад (вазыйфаи оклад) - хезмәткәргә компенсация, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь айда хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткә түләүнең билгеләнгән күләме.»;

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына бәйле хезмәт өчен бүләкләү, шулай ук компенсация түләүләре (компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән нормаль шартлардан тайпылган шартларда, махсус климат шартларында һәм радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә эшләгән өчен, һәм компенсация характерындагы башка түләүләр) һәм стимуллаштыру түләүләре (стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре);»;

2) 3 пунктта:

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Директор һәм хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган премия һәм башка бүләкләү түләүләре төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча билгеле бер вакыт эчендә (ай, квартал, ел) юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга һәм башка нигезләргә бәйле рәвештә, директор өчен - Башкарма комитет карары, хезмәткәрләр өчен - учреждениенең локаль актлары белән билгеләнә.»;

- өченче абзацта «карарлар» сүзен «карарлар белән» сүзләренә алыштырырга;

3) 5 пунктның 1 пунктчасында «мәгълүмати-методик бүлекләр» сүзләрен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

4) 6 пункттагы таблицаның «Беренче квалификация дәрәҗәсе» юлында:

- «Учреждение директоры урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «16 801,0» саннарын төшереп калдырырга;

5) 8 бүлектә «методик бүлекләр» сүзләрен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

6) 3 бүлек исемендә «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

7) 9 пунктта:

- беренче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- дүртенче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- алтынчы абзацта:

1. «мәгълүмати-методик бүлекләр» сүзләрен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

2. «һәм директор урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 4 бүлек исемендә «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

9) 12 пунктта:

- беренче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- 1 пунтчада «мәгълүмати-методик бүлекләр» сүзләрен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

- 4 пунтчадагы 3 нче таблицада «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

10) 17 пунктта:

- беренче абзацта «оешма» сүзен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

- икенче абзацта «оешма» сүзен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

11) 18 пунктта:

- беренче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- икенче абзацта «Учреждение җитәкчеләренә» сүзләрен «Учреждение директорына» сүзләренә алыштырырга;

12) 19-20 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Учреждение директорына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр билгеләү өчен эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләү тәртибе Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

20. Учреждениенең өлкән методистына һәм методистына башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләү төп эш урыны буенча аерым чорда эш нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

Өлкән методист һәм методистка түләүләрне гамәлгә ашыру өчен эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары, эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийларының зурлыгы һәм түләү шартлары учреждениенең локаль актлары белән раслана.»;

13) 21 пунктта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

14) 27 пунктта:

- беренче абзацта «мәгълүмати-методик бүлекләр» сүзләрен «учреждение» сүзенә алыштырырга;

- 12 нче таблица исемендә «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- 12 таблицада:

«муниципаль берәмлекләр мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек, структур бүлекчә мөдире (башлыгы) урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

«һәм директор урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

15) 28 пунктны көчен югалткан дип танырга;

16) 29 пунктта:

- бишенче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

- җиденче абзацта «директор урынбасары» сүзләрен «өлкән методисты» сүзләренә алыштырырга;

17) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары):

| Бердәм тариф челтәренең түләү | Тариф | Тариф ставкалары (окладлар), |
|---|---|---|

| разрядлары | коэффициентлары | сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 15 279 |
| 2 | 1,0159 | 15 522 |
| 3 | 1,0323 | 15 773 |
| 4 | 1,0480 | 16 012 |
| 5 | 1,0656 | 16 281 |
| 6 | 1,0827 | 16 543 |
| 7 | 1,1010 | 16 822 |
| 8 | 1,1187 | 17 093 |
| 9 | 1,1363 | 17 362 |
| 10 | 1,1553 | 17 652 |
| 11 | 1,1736 | 17 931 |
| 12 | 1,1933 | 18 232 |
| 13 | 1,2129 | 18 532 |
| 14 | 1,2325 | 18 831 |
| 15 | 1,2528 | 19 142 |
| 16 | 1,2738 | 19 462 |
| 17 | 1,2947 | 19 782 |
| 18 | 1,3163 | 20 112.». |

1. Шәһәр Советының 2020 елның 6 февралендәге 36/5 номерлы Карары белән расланган «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2021 елның 27 декабрендәге 11/7, 2022 елның 8 дкабрендәге 18/7 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 54 пунктта «Аерым мәгариф оешмалары җитәкчеләренә, аерым мәгариф оешмалары җитәкчеләре урынбасарларына, баш хисапчыларга,» сүзләреннән сон «аерым оешмаларның локаль актлары белән билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

2) 55 пунктта «, җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчылары» сүзләрен төшереп калдырырга

2. Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2020 елның 11 августындагы 41/8, 2021 елның 27 декабрендәге 11/7, 2022 елның 23 июнендәге 15/9, 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 86 пунктта «урынбасарларына, баш хисапчыларга,» сүзләреннән сон «спорт резервы оешмаларының локаль актлары белән билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

2) 87 пунктта «Спорт резервы әзерләү оешмалары җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлеге критерийлары һәм аларның зурлык коэффициентлары» дип үзгәртергә.

3. Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/9 номерлы Карары белән расланган физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6, 2019 елның 23 маендагы 31/6, 2020 елның 11 августындагы 41/8, 2021 елның 27 декабрендәге 11/7, 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарлары редакциясендә), 54 пунктта «аларның» сүзеннән соң «локаль актлар белән билгеләнгән» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

4. Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10 номерлы Карары белән расланган яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы, 2019 елның 1 августындагы 32/7, 2021 елның 27 декабрендәге 11/7, 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 63 пунктта «аларның» сүзеннән соң «локаль актлар белән билгеләнгән» сүзләрен өстәргә;

2) 64 пунктта «җитәкчеләргә» сүзен «җитәкчеләрнең» сүзенә алыштырырга.

5. Шәһәр Советының «Муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 10 августындагы 26/9 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2021 елның 27 декабрендәге 11/7, 2022 елның 22 августындагы 16/6, 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Мәдәният, сәнгать һәм кинематография, китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял итү муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

- түбәндәге эчтәлектәге 31.1 пункт өстәргә:

«31.1. Учреждение җитәкчесенә башка премия (бүләкләү) түләүләре төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча билгеле бер вакыт эчендә (ай, квартал, ел) юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга һәм Башкарма комитет карары белән билгеләнгән башка нигезләргә бәйле рәвештә билгеләнә һәм хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнелә.».

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль башкару сәнгате учреждениеләре мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре

хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

- түбәндәге эчтәлектәге 31.1 пункт өстәргә:

«31.1. Учреждение җитәкчесенә башка премия (бүләкләү) түләүләре төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча билгеле бер вакыт эчендә (ай, квартал, ел) юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга һәм Башкарма комитет карары белән билгеләнгән башка нигезләргә бәйле рәвештә билгеләнә һәм хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнелә.».

6. Әлеге Карар рәсми бастырылган үз көченә керә, 1 пунктның 17 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

7. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев